**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТРОИЦКО-УРАЙСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422657, РТ , Рыбно-Слободский район
с.Троицкий Урай
ул. Школьная, дом 4

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТРОЙ-УРАЙ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕНЕҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422657, ТР,Балык Бистәсе районы,
Трой-Урай авылы
Мәктәп урамы, 4 нче йорт

Тел.: (84361) 24320, факс: (84361)24320, e-mail: Tur.Rs@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17.10.2019 г. с. Трои-Урай авылы № 14

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Трои-Урай авыл җирлегенең Трои-Урай авыл торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге ”Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 45-ЗРТ номерлы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Трои-Урай авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 22 маддәсе нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Трои-Урай авыл җирлегенең Трои-Урай авыл торак пунктында үзара салым кертү буенча гражданнар җыенының беренче этабын 2019 елның 1 ноябрендә 14 сәг. 00 минутка билгеләргә.
2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Трои-Урай авыл җирлегенең Трои-Урай авыл торак пунктында үзара салым кертү буенча гражданнар җыенының икенче этабын 2019 елның 1 ноябрендә 16 сәг. 00 минутка билгеләргә.

3. Гражданнар җыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген бүлү территориаль билге буенча гамәлгә ашырылуын расларга.
4. Гражданнар җыены каравына куела торган сорауны расларга:

Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Трои-Урай авыл җирлегенең Трои-Урай авыл торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан гайре) 300 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган

средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:

1. Троицкий Урай авыл җирлеге торак пунктлары чикләрендә юлларны ремонтлау һәм карап тоту.
2. Троицкий Урай авыл җирлегендә православие зиратын төзекләндерү.
3. 4 данә евроконтейнерлар сатып алу һәм Гремячка авылында контейнер мәйданчыгына козырь урнаштыру.
4. Авыл җирлегендә энергия саклаучы яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру.

“ЯКЛЫЙМ” “КАРШЫ”

6. Әлеге карарны дәүләт теркәвеннән соң Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Трои-Урай авыл җирлегенең түбәндәге адрес буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында урнаштырырга: Трои-Урай авылы, Прикамская урамы, 9 йорт, Гремячка авылы, Александрова урамы, 24 йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда.

7. Карар басылып чыккан (халыкка белдерелгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Трои-Урай авыл җирлеге башлыгы Р.Х.Сафин